Literature

Әдәбият

Литература

DOI: 10.26907/2311-2042-2025-25-2-34-45

# TATAR FOLK LYRICAL SONGS OF THE GREAT PATRIOTIC WAR

**Liliia Khatipovna Mukhametzianova,**
G.Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of Tatarstan Academy of Sciences,
12 K. Marx Str., Kazan, 420111, Russian Federation,
lilmuhat@mail.ru.

This study reviews the Tatar folk song heritage of the Great Patriotic War, identifying characteristics of the wartime lyric songs common among the Tatars in the former USSR, elucidating their place and role in the system of national lyric folklore. The review is based on the texts introduced into the scientific circulation in the academic publications “Tatar Folk Art”, as well as expedition materials from different years stored in the Miras-Khane Written Heritage Center of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan. The article defines the primary function of wartime songs as a reflection of the spiritual world, revealing the experiences of an individual among other Tatar people. In accordance with the trends of the times, a spirit of elation and labor enthusiasm in the name of a great victory were heard on the home front. The study proves that the texts show a renewal of the national epic tradition.

**Key words**: Tatar folklore, period of the Great Patriotic War; folk lyrical art, song genre

**For citation:** Mukhametzianova, L. Tatar folk lyrical songs of the great patriotic war // Tatarica. 2025. № 2 (25). pp. 34–45. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-34-45

Tereze tobem chachakle,
(My windowsill is full of flowers)
Ostal ostem gol gena;
(There are only plants on my table)
Zhinarga bulgach zhinarga,
(If we’re going to win,
We are to win)
Beznen telak ber gena
(We have only one wish)
(*Tatar folk song)*

## Introduction

Events that make people’s souls tremble constantly occur in our lives, and their echoes take the form of folk art works. The Great Patriotic War of 1941–1945 was one of those historical events that left a deep and indelible mark on the people’s lives. The people perceived this war as an event that turned their lives upside down. It is well known that there is not a single home, not a single family untouched by the military catastrophe. Some went to the front and took up arms to fight the enemy, others were forced to leave their homeland and resettle, and for many, hard labor began in the rear, they never took their eyes off the front, compounded by the pain of losing their loved ones. At the same time, the dramatic changes

that occurred in people's lives created entirely new conditions for the development of Tatar folk art. The catastrophe that befell the country greatly strengthened such qualities as patience, humility, endurance, patriotism, and hard work, which run in the Tatar bloodline. The hardships of war awakened deep feelings buried in the hearts of the people for centuries. All this contributed to the revival of our spiritual heritage, covered with the dust of history, enriching Tatar folklore with entirely new examples characteristic of its time.

During the Great Patriotic War, the song genre was very active in Tatar folk art. Tatar songs reflected the thoughts, desires, and experiences of our people, and this is also true of the lyrical works of the war years. Despite the harshest living conditions, folk songs lived on, warming people's hearts and calling for perseverance. "Even in the most difficult and gloomy days, when the fate of the country was being decided, songs filled with genuine faith in victory resounded in the folk language," wrote I. Nadirov, Ph.D. in Philology and an expert in the song genre of the Tatar people [1, p. 93].

Each of the lyrical songs, cited as examples of the ideas expressed in the article, is rich in content and multifaceted in imagery. The historical past and ethnographic characteristics of the Tatar people, their social life, family and everyday relationships, the ideas of fighting for the Motherland, liberating the loved ones from enemies, and the embodiment of heroism acquired greater significance in the lyrics during this time crucial for the country. These songs reflect the feelings experienced by the Tatar people, the emotions left behind by the events of that era, the traits of the national character, and the great hope for victory even in the most difficult times.

## Materials and methods of research

For research, the author primarily uses the academic volumes "Tatar Folklore" (1976, 1980, 1988) and the folklore collection, held at the Center for Written Heritage of the G. Ibragimov Institute of Language, Literature, and Art, the Tatarstan Academy of Sciences. The information on materials, recorded from informants, highlights the vast geographic distribution of Tatars and the free circulation of Tatar folk songs throughout the former Soviet Union. Numerous song variants, associated with the war period, serve as a reminder that, while scattered across a vast territory, the people once shared a single thought, mourned a single sorrow, and maintained a unified, firm opinion on a particular event.

The issue of Tatar people's lyrical songs, created during the difficult war years, requires an approach from the perspective of the nation and the destiny of the people. Therefore, the methodological basis of our article is the principle of the nationalist and historical approach to the songs from the Great Patriotic War and their lyrical genre. The study of Tatar folklore by era, that is, examining folk art from a historical perspective, has been used in Tatar folklore studies since the late 20th century. This experience was reflected in the published monographs, devoted to works of Tatar folk art [2], in preparation of dissertations [3], in selection of folklore works relating to a certain era, in academic volumes chronologically covering the literary and cultural development, in their scientific analysis [4], etc. At the beginning of the 21st century, a textbook-monograph by Doctor of Philology F. Urmancheev [5] was compiled and published for universities and colleges. It is intended for the study of Tatar folk art by dividing it into separate historical periods, which indicates that the identification of Tatar folklore, specific to a certain period, has recently been raised to the appropriate scientific level and systematized.

The relevance of this research article is the popularity of the song genre in Tatar folk art, its status as one of the most "lively" and active examples of folklore among other genres, as well as the special significance of lyrical folklore during the years of war, a critical situation facing the people. Although the theme of the Great Patriotic War songs has attracted considerable attention since the 1950s [1; 2; 5, pp. 323–327; 6; 7; 8], its rethinking in our time is due, firstly, to the ideological and political nature of the event; secondly, to the need to rethink popularized and widespread folklore works associated with the Great Patriotic War.

## Discussion

As often happens, during the war years, lyrical poetry came to the fore, imbued with ideas of hatred for the enemy who had invaded our native land, love for the Motherland, and the struggle for its freedom. Lyrical songs have always held a special place in Tatar folklore. Due to the events of the Great Patriotic War, they acquired a completely new sound and began to fulfill a special function in the life of the people.

Long lyrical songs are multi-stanzaic, narratively complex, synthetically musical, and

poetic. Short lyrical songs differ from long melodic songs in their poetic structure, melody, and theme. The quality that undoubtedly unites both long melodic songs and songs composed of short quatrains is, of course, lyricism. In lyrical works, which became widespread during the war, a subjective attitude toward someone or something is expressed through personal experiences, the singer's state of mind, and mood. Lyricism reveals feelings in sentiments, moods, and subtle nuances of the emotional principle; it has the character of emotionality, poetic excitement, and insight. During the war years, such immortal songs as "Sarman buylary" ("Along Sarmanovo"), "Koshlar kebek" ("Like Birds"), "Sugyshchy zhyry" ("A Soldier's Song"), "Archa" ("Arsk"), "Su buylap" ("Along the River"), "Oy artynda shomyrtym" ("A Bird-Cherry Tree behind My House"), and "Ramay" ("Ramay") gained widespread popularity with the people. Frequent radio broadcasts also contributed to getting these songs etched on in the people's memory, to passing them on by word of mouth, and to being performed by both ordinary people and amateur singers.

During the Great Patriotic War, lyrical poetry, as a form of expressing feelings, shaped the people's attitude toward the difficulties that arose, serving as a means of spiritual relief. For example, there is every reason to believe that the well-known folk song "Aktanysh Basmalary," copied from the Tatarstan Radio Library in 1960, became popular in connection with the events of the Great Patriotic War. The song mentions the attributes of the native land – the Agidel (Belaya) River, the Aktanysh footbridge, the fluttering ribbons in the girls' braids, the shifting ice floes in April, etc. – emphasizing the heroes' courage and praising those who returned victorious to their Motherland:

Kayan barsan, shunnan tury
(Wherever you go, from there)
Aktanyshnyn yullary;
(Aktanysh roads lead straight ahead;)
Doshmannarny zhinep kaytty,
(Having defeated the enemy)
Beznen rayon ullary
(the Sons of our region have returned) (Here and after the lyrics is abridged) [9, p. 341].

Another song "Batyr egetka" ("To the Brave Young Man"), recorded in 1955 from the personal archive of the People's Artist of Tatarstan Gulsem Suleimanova, was one of the most popular songs of the Great Patriotic War:

Dustym, chachlaren bodra,
(My friend, your hair is curly,)
Arasynnan zhil ora;
(The wind ruffles it;)
Maturlygyn gazhap tugel,
(You aren't so handsome)
Batyrlygyn soydera.
(Your bravery is more attractive.)
Oy artynda almagachym
(There is an apple tree behind my house;)
Alsu chachaklar atty;
(Blooming with pink flowers)
Minem irkam geroy bulyp
(My beloved has returned as a hero)
Sugysh kyrynnan kaytty
(From the battlefield) [9, p. 347].

Among such songs there are many created by professionals, the songs which subsequently became folk ones. For example, these songs are "Sagynu" ("Sorrow") and "Yuksynu" ("Sadness"). This group of war songs is filled with complete confidence in the coming victory, the valiant defense of the Soviet country and, perhaps, "red" ideas that are not very characteristic of folk art. Nevertheless, these songs were and are still found in the folk repertoire. They could be heard everywhere – in the villages and in the cities, among the young and old people, in amateur art clubs, in front of the front-line soldiers. The distribution and popularization of ideological folk songs was influenced by the fact that at that time, they were often performed by professional artists. In their compositional structure and artistic development, they have become the songs of national treasure. The songs, whose creation is associated with the Great Patriotic War, are the works that are closely associated with the ideological ideas of the era, those which put patriotic feelings to the fore.

In wartime songs, the focus was on civilian lyrics, humility in difficult times, on courage and valor on the battlefields. The unbending spirit was especially emphasized in short lyrical songs characteristic of wartime. These works, occupying a significant part of the Tatar folk song fund, were collected by I. Nadirov in the form of a separate academic volume, dedicated to folk songs, which included 120 songs on the theme of the Great Patriotic War [10, pp. 365–373]. The lyrical songs, recorded by the Tatars during the war in the rear, at the frontline and in the Donbass temporarily occupied by the enemy, speak of our compatriots' resilience in difficult trials by depicting the behavior of the Tatars in historical chronicles. In this way their feelings have reached the present day.

The songs about the relationships between young people during the Great Patriotic War often mention hard work and dedication of young men or women, and their feeling of love manifesting itself in hard work:

Minem irkam brigadirka,
(My beloved is the foreman,)
Kukragenda medale;
(She has a medal on her chest;)
Kazanda da, Maskauda da
(Both in Kazan and in Moscow)
Belmagannar yuk any
(There is no one who doesn't know her) [9, p. 353].

This song, called "Minem irkam" (My Beloved), was recorded in 1953 by Roza Arslanova (born in 1938) from the village of Urgagar, the Alki District of Tatarstan, and it was included in the Tatar folk song fund. Owing to the songs, in the harsh conditions of that time, people realized that the main quality that determined the social essence of a person was their attitude to work. In those years, the struggle for victory was not easy even in the rear, which is well indicated by folk songs. The real heroes who worked in the rear were, in fact, women. In the lyrical song, it is the chanting of a beautiful, slender girl praising her achievements in physical labor that reflects the spirit of the wartime.

Even in the face of war, the people who sang to relieve their soul included a large number of works consonant with the spirit of the times in their repertoire. Along with songs imbued with heroism and patriotism, the songs imbued with feelings of deep sadness, grief, separation, longing, and love define the folk art basic flavor of that period. A soldier who went to the frontline to defend his country, or his beloved one who had seen him off, yearned for the loved one and hoped for a new meeting:

Kama syu sina tanysh tugel,
(The Kama's waters are unfamiliar to you,)
Yalgyz gyna toshep buylama;
(Don't go down alone;)
Ara erak, katlar ozak yori,
(Don't think the distance is long,)
Onytkandyr diep uylama.
(Your letters take too long and he has forgotten you.)
Buylarynda bik kup yoresam da,
(Although I have walked along its shores many times,)
Khich tuyalmyim yamle Kamadan;
(I will never get tired of the beautiful Kama;)
Makhabbatem Kama kebek tiran,
(My love runs deep like the Kama does,)
Ochrashyrbyz ale yanadan [9, p. 338].
(We will meet again)

This song called "Kama bue" ("The Kama's Bank") was recorded in 1955 by Sariya Nogmanova (born 1928) in the village of Burunduki, the Kaybitsky District of Tatarstan.

Or the song "Sarman" ("Sarmanovo"), recorded by Sania Gataullina in 1961 in the village of Sheremetyevo, the Sheremetyevo District of Tatarstan, which also reflects the sincere feelings inherent in ordinary people who have learned all the bitterness of war, which can muddle their fates and bring deprivation:

Sarman buylarynda salkyn zhillar,
(Cold winds along the banks of the Sarman River,)
Tunam, irkam, tunam, tunyn bir;
(I'm freezing, darling, freezing, give me your fur coat;)
Aerylabyz, irkam, aerylabyz,
(We are parting, my love, we are parting,)
Saubullashyik inde, kulyn bir.
(Let's say goodbye, give me your hand.)
Sarman buylaryn min buyladym,
(I walked along the Sarman River,)
Buylaganda sine da uyladym.
(While I walked, I was thinking about you,)
Kitkan chaklarynda kul birmadem,
(I didn't give you my hand when you left,)
Tagyn kaytyrsyn dip uyladym
(I thought you would come back) [9, pp. 341–342].

The fact that this song had versions, recorded in 1955 by Sariya Askarova in the village Burunduki of the Kaybitsky District of Tatarstan and in 1969 by Maira Khalilova (born 1938) in the village of Uba, the Bolsherechensky District of the Omsk Region, is clear evidence that it was quite popular at that time.

The songs, composed by soldiers at the front-line during that period should be singled out in a separate group of lyrical works related to the Great Patriotic War. For example, "Ilne sagynu zhyry" ("The Song of Homesickness") was recorded in 1958 by Abdullah Utyameshev (born 1899) in the village of Tarakan, the Bednodemyansky District, the Republic of Mordovia:

Kyrda karchygalar kagynyp yori,
(In the field, hawks wave their wings,)
Koymaslarmy kyrlat tarysyn?
(Will millet ears scatter grains?)
Karchyga (Hawk),

Kuresha almyicha kunelem talchyga.
(My soul hurts without dating.)
Ilen sagynasynmy dip soryisyn,
(You will ask if I miss my homeland,)
Kurmisrnme yozemnen sarysyn?
(Don't you see the yellowness in my face?)
Karchyga (Hawk),
Kuresha almyicha kunelem talchyga.
(My soul hurts without dating.)
Kychkyrmachy, kakkuk, sin kychkyrma,
(Don't shout, cuckoo, don't you shout,)
Echkenaemne minem poshyrma!
(Don't shake my soul,)
Kakkugem,
(Cuckoo,)
Chit zhirlarda uta yashlegem!
(My youth is passing abroad.)
Il genama kaytyp, sougan belan
(Will there be time when I return to my homeland)
Ber kavyshyr konnar bulyrmy?
(And see my beloved?)
Kakkugem,
(Cuckoo,)
Chit zhirlarda uta yashlegem!
(My youth is passing abroad) [9, p. 127].

Songs written during the wars preceding World War II became popular again among soldiers during that period. For example, the song "Okop koe" ("The Trench Song") was published in 1941 in A. Klyucharev's collection "Tatar khalyk koilare" ("Tatar Folk Songs") [11, p. 94]. According to the given note, this work was already known during the Russo-Japanese War. The stanza coming with notes in A. Klyucharev's collection looks like this:

Soldatskiy remen belan
(A soldier's belt)
Budylar bellaremne shul.
(They tied at my waist.)
Yogerep kitarday bulam la,
(I feel like running away.)
Chit illarda uta gomerem,
(My life is passing abroad,)
Sagyndym illaremne shul.
(I miss my country so much) [11, p. 94].

Under the title "Kozge achy zhillirda" ("In the Autumn Bitter Winds"), this song was included in A. Abdullin's songbook transferred to the Heritage Fund of the Institute of Language, Literature and Arts named after G. Ibragimov, the Academy of Sciences of Tatarstan in 1960, its text is stored in the folklore center [12].

The next song, "Soldat zhyry" ("The Soldier's Song"), was recorded on a tape recorder in 1970 in the village of Baikal (Bukhara) of the Nizhnetaudinsky District, the Tyumen Region near Sabitova Sarbi (born 1895) (recording and notation by I. Kadyrov). It was still sung in the 1970s, so it is quite clear why it was very popular after the Great Patriotic War:

Chuen chulmak, auzy tar la,
(The narrow-mouthed iron pot)
Peshar soldat ashlary la;
(To cook a soldier's meal,)
Kosh-kort ochyp zhitmas zhirga,
(Where birds and insects will not fly)
Kita soldat bashlary la.
(And where soldiers' heads fly away)
Tash kazarma buylaryna
(To the stone barracks,)
Myltygymny soyadem;
(I'll lay my rifle down)
Tugan-uskan illarema
(On my native land)
Kaychan kaityr soyagem?
(When my bones come back) [10, pp. 157–158].

This song is an old soldier's song, most likely reflecting the fate of the Tatars in the tsarist army in the old days. It was apparently "revived" during World War II in connection with the events mentioned in the song.

Speaking of front-line songs, it is necessary to highlight one more phenomenon that complements Tatar lyrical folklore. This is the development of the epistolary genre in Tatar folk art during the Great Patriotic War. Written correspondence is one of the traditions that has always occupied a significant place in the life of educated Tatars. It is known that during the war, communication by letters was maintained between the front and the rear. "According to the ancient custom, corresponding between the front and the rear, people decorated their letters with songs," wrote I. Nadirov [1, p. 93]. Indeed, the extreme popularity of the song genre is evident in the soldiers' letters to their loved ones, and the lyrics are often found in letters from the front. In these lines, the Tatar soldiers, in an aphoristically laconic, simple, but at the same time highly artistic manner, expressed their attitude towards their country, their feelings for loved ones who sincerely believed in the unshakable unity of the Soviet people and those who fought for their homeland. The materials, preserved in the newspapers of those years, indicate that home front workers also

decorated their letters to front-line soldiers with lyrics:

Beznen avyl urtasynda
(In the center of our village)
Zhilferdi Kyzyl alam;
(The red flag is flying;)
Ilebez ochen korashuche
(Glory to the heroes)
Kakharmannarga salam!
(Fighting for our country!) [7, p. 367].

Although we are talking about wartime songs of 1941–1945, this type of art covers a significant length of time. It is impossible to establish a strict framework for them: for example, the songs that were created only in connection with military events and were performed only during the war. Some of the songs are the works known even before the Great Patriotic War, they have not lost their popularity today. These are the gems that were with the people both in the rear and at the front, helping in difficult times and giving spiritual strength during the years of war.

Wartime songs are a hymn to heroism and beauty. During the Great Patriotic War, the poetic work of the Tatar people was enriched with such long, melodic, and countless short lyrical songs as "Oy artynda shomyrtym" ("The Bird Cherry Tree behind My House"), "Tan atkanda" ("At Dawn"), "Ozatu" ("Seeing Off"), "Minem irkam armyada" ("My Beloved One Is in the Army"), "Zombel chachak" ("The Hyacinth Flower"), "Kotam ale" ('I'm Still Waiting"), "Bondyug" ("Bondyug"), "Zoya" ("Sviyazhsk"). These and other songs have stood the test of time and have come to this day in several versions. Many of them are still sung today.

## Conclusions

During the years of war, the richness of song poetry was due, firstly, to its connection with ancient poetic traditions, secondly, to the popularization through the media of the most successful creations of poets and composers, as well as the performance of folk works by professional singers. Even in difficult times, songs were not forgotten, meaning that the song poetic ornaments carried people over into the new era. Thus, the works, performed since ancient times, have been passed over into the future. Of course, not every song, performed during the war, deserves such a reputation, but most of them have indeed stood the test of time and survived to this day. As is typical of this genre, the ease with which songs come to mind in various situations and their frequent performance by people made this type of folk music an inseparable companion of those hard times. The works, which in their content and theme can be considered wartime songs, were recorded or preserved in written sources in various regions inhabited by the Tatars. The works of lyrical folklore, that could be heard from the Volga Region to the vast expanses of Siberia, deserve to be considered intangible monuments to the unity, strength of spirit, patience, and richness of feelings of the Tatars during the years most difficult for the country.

**References**

1. Nadirov, I. (1957). *Boek Vatan sugyshy yellarynda Tatars khalyk zhyrlary* [Tatar Folk Songs during the Great Patriotic War]. Kazan Utlary. No. 3, pp. 93–98. (In Tatar)

2. Nadirov, I. (1961). *Khalyk ham zhyr: Boek Vatan sugyshy chorynda Tatar khalyk poetic izhaty* [The People and the Song. Tatar Folk Poetic Art during the Great Patriotic War]. 192 p. Kazan, Tatar. kit. nashr. (In Tatar)

3. Zakirova, I. G. (2000). *Narodnoe tvorchestvo Bulgarskogo perioda: dis. ... k. fil. n.* [Folk Art of the Bulgarian Period: Ph.D. Thesis Abstract]. Kazan, 24 p. (In Russian)

4. Mukhammetzyanova, L. Kh. (2002). *17-18 gasyrlarda khalyk izhaty* [Tatar Folk Art in 17–18 Centuries]. Tatar adabiyaty tarikhy. In 8 vol. Vol. 2, pp. 227–243. 15–18 gasyrlar (təz. həm fənni məkh. G. M. Davletshin). Kazan, Tatar. kit. nashr. (In Tatar)

5. Urmanche, F. I. (2002). *Tatar khalyk izhaty: yugary uku yortlary ham colleglar ochen dareslek* [Tatar Folk Art: A Textbook for Universities and Colleges]. 335 p. Kazan, Magarif. (In Tatar)

6. *Sugysh uty belan otelgan yazmyshlar. Frontovik yazuchylarnyn khatlary ham bulaklau kagazlare zhyentygy* (2014) [Fates Ruined by the Flames of War. Collection of Letters and Award Papers of Front-Line Writers]. 625 p. Təz., iskərmələr avtory A. Shamova. Kazan, Ikhlas. (In Tatar)

7. *Utly yellar kaitavazy. Boek Vatan sugyshy chorynda Tatars khalyk izhaty* (2005) [Echoes of the Fiery Years. Tatar Folk Poetic Art during the Great Patriotic War]. Keresh sүz avtory F. I. Urmancheev. 199 p. Kazan, Tatar. kit. nashr. (In Tatar)

8. Mukhammetzyanova, L. Kh. (2025). *Dakhshatle chor yuldashlary. Tugarak uen* [Tough Times Fellow Travelers. A Round Game]. No. 2, pp. 26–32. (In Tatar)

9. *Tatars khalyk izhaty. Tarihi ham lyrical zhyrlar* (1988) [Tatar Folk Art. Historical and Lyrical Songs]. Tomny təzүche, keresh məkalə yazuchy, iskərmələrne əzerləүche I. N. Nadirov. 488 p. Kazan, Tatar. kit. nashr. (In Tatar)

10. *Tatars khalyk izhaty. Kyska zhyrlar* (1976) [Tatar Folk Art. Short Songs (Quatrains)]. Sost. I. N. Nadirov. 488 p. Kazan, Tatar. kit. nashr. (In Tatar)

11. Klyucharev, A. S. (1941). *Tatars khalyk koilare. 1nche kitap* [Tatar Folk Melodies, 1st Book]. Tøzүchese həm җyyuchysy A. S. Klyucharev. 248 p. Kazan, Tatar. kit. nashr. (In Tatar)

*12. Kozge achy zhillirda* (1960) [In the Bitter Autumn Winds]. TFA G. Ibrahimov isemendəge TƏhSInen̡ Yazma miras үzəge, FF, koll. 1, p. 34a, sak. ber. (In Tatar)

13. Kadyrov, I. Sh. (2021). *Tatars khalkyn tuy zhyrlary. Seber arealy* [Wedding Songs of the Tatar People. Siberia]. 188 p. Kazan, IALI. (In Tatar)

# БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЧОРЫ ТАТАР ХАЛЫК ЛИРИК ҖЫРЛАРЫ

**Лилия Хатип кызы Мөхәммәтҗанова,**
Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов ис.
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты,
Россия, 421111, Казан ш., К. Маркс ур., 12 нче йорт,
lilmuhat@mail.ru

Җыр – халык лирикасының сүз һәм көй үрелешенә нигезләнгән иң популяр төре. Тикшеренүдә Бөек Ватан сугышы чорының татар фольклор җыр мирасына күзәтү ясала, сугыш елларында лирик җырларның элеккеге СССР территориясендә сибелеп яшәгән татарлар арасында үсеше һәм таралышының үзенчәлеге билгеләнә, аларның милли лирик фольклор системасындагы урыны һәм роле ачыклана. Хронологик алымга таянып, татарларда лирик фольклорның сугыш елларында ике төп юнәлештә – тылдагы халык җырлары һәм фронттагы халык җырлары буларак үсеш алуы күрсәтелә. Автор сугыш чоры җырларының төп функциясен рухи дөньяны чагылдыру дип билгели, аерым шәхес кичерешләренең тулаем татар халкына хас булуын күрсәтә; сугыш елларында актуаль булган җырларда күп төсмерләрдә кешелекнең төп хисләре – кайгы, сагыш, газап, мәхәббәт, аерылышу һәм якты киләчәккә өмет гәүдәләнеш тапкан булуны ачыклый. Татар халкының бу чорга караган җырларында дошманны һичшиксез җиңүгә пропаганда сизелә, заман тенденцияләренә яраклы рәвештә, бөек җиңү хакына тылда күтәренкелек һәм хезмәт энтузиазмы рухы яңгырый.

**Төп төшенчәләр**: татар фольклоры, Бөек Ватан сугышы чоры, халыкның лирик иҗаты, җыр жанры

**Сылтама өчен:** Мөхәммәтҗанова Л. Х. Бөек Ватан сугышы чоры татар халык лирик җырлары // Tatarica. 2025. № 2 (25). 34–45 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-34-45

Тәрәзә төбем чәчәкле,
Өстәл өстем гөл генә;
Җиңәргә булгач, җиңәргә,
Безнең теләк бер генә.
*(Татар халык җыры)*

## Кереш

Халкыбыз күңелен тетрәндерерлек вакыйгалар яшәеш-көнкүрештә әледән-әле килеп чыга тора, аларның кайтавазы халык иҗаты әсәрләре булып формалаша. 1941–1945 елгы Бөек Ватан сугышы да – халык тормышында җуелмас тирән эз калдырган тарихи вакыйгаларның берсе. Халык аны тормышының астын-өскә әйләндергән вакыйга буларак кабул итә. Сугыш афәте кагылмаган бер генә йорт та, бер генә гаилә дә калмавы мәгълүм. Кемнеңдер кемедер фронтка китеп, дошманга каршы кулына корал алып көрәшә башлый, кемдер туган җирен ташлап, каядыр күченергә мәҗбүр була, ә күпләр өчен фронтны бер генә минутка да күздән ычкындырмаган авыр тыл хезмәте башлана, моңа сугышта газизләрен югалту ачысы да өстәлә. Шул ук вакытта кеше тормышына бәреп килеп кергән кискен үзгәрешләр татар халык иҗаты үсеше өчен өр-яңа шартлар тууга да сәбәпче була. Ил өстенә килгән афәт татарларның канында булган сабырлык, күндәмлек, чыдамлык, ватанпәрвәрлек, эшчәнлек сыйфатларын бик нык көчәйтеп җибәрә. Сугыш вакытындагы тормышның авырлыгы халыкның күңел төпкелендә элек-электән яткан тирән хисләрне кабат уята. Болар барысы тарих тузаны баскан рухи мирасның кабат тергезелүенә, активлашуына китерә, татар фольклорын чорына хас өр-яңа үрнәкләр белән баета.

Бөек Ватан сугышы чоры татар халык иҗатында җыр жанры үтә актив була. Татар

җырларында халкыбызның күңел түрендә йөргән уй-теләкләре, борчу-мәшәкатьләре чагылыш тапкан, әлеге закончалык сугыш чоры лирик иҗатына да кагыла. Тормыш шартлары бик авыр булуга карамастан, халык җырлары яшәвен дәвам иткән, халыкның күңелен юаткан, кешеләрне бирешмәскә өндәгән. «Ил язмышы хәл ителгән иң авыр һәм шомлы көннәрдә дә халык телендә җиңүгә якты ышаныч белән сугарылган җырлар яңгырый», – дип язды бу хакта филология фәннәре кандидаты, татар халкының җыр жанры белгече И. Надиров [1, б. 93].

Мәкаләдә әйтелгән фикерләргә мисал буларак телгә алынган лирик җырларның һәркайсы эчтәлек ягыннан бай мәгънәле, образлары күпкырлы. Татар халкының тарихи үткәнен һәм этнографик үзенчәлекләрен, иҗтимагый тормышын, гаилә-көнкүреш мөнәсәбәтләрен һәм үз җире өчен көрәшкә омтылу, якыннарын дошманнардан азат итү идеяләрен алга сөреп, батырлыкны лирика аша сурәтләгән юлларның әһәмияте ил, ватан өчен хәлиткеч заманда тагын да арта. Бу җырларда татар кешесе кичергән хисләрне, чор вакыйгалары үз эзен салган тойгыларны, бик авыр вакытларда да җиңүгә булган зур өметне һәм милли холык билгеләрен табарга мөмкин.

## Тикшеренү материаллары һәм методлары

Тикшеренү өчен материаллар җәһәтеннән автор, асылда, «Татар халык иҗаты» академик томнарына (1976, 1980, 1988) һәм Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә саклана торган фольклор фондына мөрәҗәгать итте. Информантлардан язып алынган материаллар турындагы мәгълүматлар татарларның таралыш географиясе никадәр киң булуны һәм элеккеге советлар иленең теләсә кайсы почмагында татар халык җырларының иркен яңгыравын ассызыклый. Сугыш чорына кагылышлы җырларның күп вариантлылыгы исә үз чорында милләтнең, киң территориядә сибелеп яшәп тә, бер үк уй белән януын, бер хәсрәт белән хәсрәтләнүен, билгеле вакыйгага карата бердәм ныклы фикердә торганлыгын искәртә.

Ил белән күтәргән дәһшәтле сугыш елларында татар халкына хас лирик җырлар проблемасы – милләт, халык язмышы күзлегеннән якын килүне таләп итә торган мәсьәлә. Шуннан чыгып, мәкаләбезнең методологик нигезен Бөек Ватан сугышы чорына караган җырларга, аның лирик төренә халыкчанлык, тарихилык яссылыгында якын килү принцибы тәшкил итә. Татар фольклорын чорларга бүлеп өйрәнү, ягъни халык иҗатын тарихи яссылыкта карау тәҗрибәсе XX йөздән соңгы татар фольклористикасында кулланыла килә. Әлеге тәҗрибә билгеле бер чорга бәйле татар халык иҗаты әсәрләренә багышланган монографияләр чыгаруда [2], диссертацияләр [3] әзерләүдә, әдәби-мәдәни барышны хронологик яктырткан академик томнарда теге яки бу чорга караган фольклор әсәрләрен аерып чыгарып, аларны фәнни анализлауда [4] һ.б. чагылыш таба. XXI гасыр башында филология фәннәре докторы Ф. Урманчеевның югары уку йортлары һәм колледжлар өчен төзеп бастырган дәреслек-монографиясе [5] татар халык иҗатын аерым тарихи чорларга бүлеп өйрәнүгә корылган, бу исә билгеле бер вакыт аралыгына хас татар фольклорын аерып чыгаруның соңгы чорда тиешле фәнни югарылыкка куелганлыгын, системалашканлыгын дәлилли.

Тәкъдим ителә торган фәнни мәкаләнең актуальлеген татар халык иҗатында җыр жанрының популярлыгы, фольклорның башка жанрлары арасында иң «тере» һәм актив үрнәкләрдән булуы һәм халык өчен критик ситуация тудырган сугыш чорында лирик фольклорның аеруча зур әһәмияткә ия булуы билгели. Бөек Ватан сугышы чорына хас җырлар темасына XX йөзнең 50 нче елларыннан ук шактый игътибар ителә килсә дә [1; 2; 5, б. 323–327; 6, 7, 8], аңа бүгенге көндә янә мөрәҗәгать итү, беренчедән, вакыйганың идеологик-сәяси асылына бәйле һәм, икенчедән, Бөек Ватан сугышына мөнәсәбәтле популярлашкан һәм таралган фольклор әсәрләрен яңадан күзәтеп чыгуга булган зарурияттән чыгып башкарыла.

## Фикер алышу

Вакыйгасына күрә, сугыш елларында туган илгә басып кергән дошман явына нәфрәт, үз ватаныңа мәхәббәт, аның азатлыгы өчен көрәш идеяләре белән сугарылган лирик иҗат алгы планга чыга. Лирик җырлар татар халык иҗатында гомер-гомергә аерым зур урын биләгән. Бөек Ватан сугышы вакыйгалары уңаеннан алар өр-яңа яңгыраш ала, халык тормышында үзенә бер функция үти башлый дияргә мөмкин.

Лирик озын җырлар – күп строфалы, сюжетлы, катлаулы синтетик музыкаль-поэтик лирик иҗат. Лирик кыска җырлар озын көйле

җырлардан шигъри төзелеше ягыннан, нинди көйгә башкарылулары, кайсы теманы колачлавы җәһәтеннән һ.б. яклары белән аерылып тора. Җырларның озын көйләләрен дә, кыска дүртьюллыктан гыйбарәт булганнарын да һичшиксез берләштерә торган сыйфат – ул әлбәттә, лирика. Сугыш чорында популярлашкан лирик иҗатта да шәхси тойгы аша кемгә яки нәрсәгә дә булса субъектив мөнәсәбәт белдерелә, җырлаучының хәле-халәте, кәефе гәүдәләнеш таба. Лиризм хис-кичерешләрдәге, кәеф-халәттәге тойгыны, эмоциональ башлангычтагы нәзек нечкәлекләрне аңлатып бирә; ул эмоциональлек, шигъри дулкынлану, күңелне айкау характерына ия. Сугыш елларында «Сарман буйлары», «Кошлар кебек», «Сугышчы җыры», «Арча», «Су буйлап», «Өй артында шомыртым», «Рамай» кебек үлемсез җырлар халыкта бик нык популярлашкан була. Радио аша еш яңгыраулары да бу җырларның халык хәтеренә ныграк уелуен, телдән-телгә күчеп, халык вәкилләре, үзешчәннәр тарафыннан җырлануын тәэмин иткән.

Бөек Ватан сугышы чорында лирик поэзия, хис-кичерешләрне чагылдыра торган иҗат буларак, халыкның килеп туган кыенлыкларга мөнәсәбәтен билгеле, күңел бушату чарасы булып та хезмәт итә. Мәсәлән, 1960 елда Татарстан радиосы фонотекасыннан күчереп алынган «Актаныш басмалары» исеме белән мәгълүм халык җыры Бөек Ватан сугышы вакыйгалары уңаеннан популярлашкан дип уйларга тулы нигез бар. Җырда туган илгә генә хас атрибутлар – Агыйдел суы, Актаныш басмалары, кызларның үргән чәчендә җилфердәүче тасмалар, апрельдә кузгала торган бозлар һ.б. телгә алына, аларның газизлеге ассызыклана, шулар хакына туган якка җиңеп кайткан батырлар мактала:

Каян барсаң, шуннан туры
Актанышның юллары;
Дошманнарны җиңеп кайтты,
Безнең район уллары.

(Җыр текстлары биредә һәм алга таба кыскартып бирелә) [9, б. 341].

Яисә «Батыр егеткә» җыры Татарстанның халык артисткасы Гөлсем Сөләймpraiseованың шәхси архивыннан 1955 елда күчереп алынган. Бөек Ватан сугышы чорының иң популяр җырларыннан берсе:

Дустым, чәчләрең бөдрә,
Арасыннан җил өрә;
Матурлыгың гаҗәп түгел,
Батырлыгың сөйдерә.
Өй артында алмагачым
Алсу чәчәкләр атты;
Минем иркәм герой булып
Сугыш кырыннан кайтты [9, б. 347].

Мондый төр җырлар арасында нигездә профессионаллар иҗат итеп, соңыннан халыклашып киткән җырлар күп. «Сагыну», «Юксыну» кебек җырлар моңа мисал була ала. Сугыш чоры җырларының әлеге төркемендә киләчәк җиңүгә тулы ышаныч, совет илен намус белән саклау-яклау, һәм, бәлки, халык иҗаты әсәрләренә бик үк хас булмаган «кызыл» идеяләр дә бар. Хәл бу ки, мондый җырлар халык репертуарында булган һәм алар әле безнең көннәрдә дә очрап куя. Бу төр җырлар һәркайда – авылда һәм шәһәрдә, яшьләр һәм өлкәннәр арасында, үзешчән сәнгать түгәрәкләрендә, фронтовиклар каршында яңгырый торган булган. Идеологик халык җырларының киң таралып популярлашуына үз вакытында аларның профессиональ артистлар башкаруында бик еш яңгырап торуы да йогынты ясаган. Композицион төзелешләре, сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан алар милли мирас җырлары рәтендә карала. Барлыкка килүе Бөек Ватан сугышына бәйле мондый җырлар – чорның идеологик фикерләре белән тыгыз бәйләнеш тоткан, патриотик хисләрне алга куйган иҗат.

Сугыш чоры җырларында гражданлык лирикасына зур урын бирелгән, авырлыкларга баш имәү пропагандаланган, көр күңеллелек һәм батырлыкка өндәү хупланган. Какшамас рух сугыш чорына хас кыска лирик җырларда аеруча ассызыклана. Татар халык җыр фондының шактый өлешен алып торган мондый иҗатны И. Надиров халык җырларына багышланган академик томда аерым бер шәлкем итеп туплап бирә, анда Бөек Ватан сугышы темасына караган 120 берәмлек җыр урын алган [10, б. 365–373]. Сугыш чорында тылда, фронтта һәм вакытлыча дошман кулына эләккән Донбасс өлкәсендә татарлардан язып алынган лирик иҗат милләттәшләребезнең катлаулы сынауларга бирешмәве хакында сөйли, тарихи хроникада татарларның үз-үзен тотышын интерпретацияли. Хис-кичерешләрен бүгенге көннәргә җиткерә дип бәяләргә мөмкин.

Бөек Ватан сугышы елларында яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләрне яктырткан җырларда еш кына егетнең яисә кызның эшчән булуы, хезмәт сөюе телгә алына, мәхәббәт хисләре хезмәт сөючәнлек аша яктыртыла:

Минем иркәм бригадирка,
Күкрәгендә медале;
Казанда да, Мәскәүдә дә
Белмәгәннәр юк аны [9, б. 353].

«Минем иркәм» дип аталган бу җыр татар халык җырлары фондына 1953 елда Татарстанның Әлки районы Үргагар авылында Роза Арслановадан (1938 елда туган) язып алып кертелгән. Җырда кешенең иҗтимагый асылын билгеләгән төп сыйфат буларак аның хезмәткә мөнәсәбәте саналуы ассызыклануда заманның кырыс шартлары төп рольне уйнаган. Җиңү хакына көрәшнең ул елларда тылда да җиңелләрдән булмавы халык җырлары аша җиңел тоемлана. Тылда хезмәт куючы батырлар, асылда – хатын-кызлар. Лирик җырда нәкъ менә сөйкемле сылу кызның физик хезмәттәге уңышларын мактап җырлау сугыш чоры рухын чагылдыра.

Сугыш афәте килгәндә дә җырлап күңел бушаткан халык үз репертуарына заман рухына аваздаш әсәрләрне күпләп керткән. Каһарманлык, ватанпәрвәрлек белән сугарылган җырлар янәшәсендә тирән кайгы, хәсрәт, аерылу, сагыну, ярату хисләре өстенлек алган җырлар да бу чор халык иҗатының төп колоритын билгели. Илне сакларга фронтка киткән сугышчы яисә аны озатып калган яры сөйгәнен уйлап сагышлана, кабат күрешүгә өметләнә:

Кама суы сиңа таныш түгел,
Ялгыз гына төшеп буйлама;
Ара ерак, хатлар озак йөри,
Оныткандыр диеп уйлама.
Буйларында бик күп йөресәм дә,
Һич туялмыйм ямьле Камадан;
Мәхәббәтем Кама кебек тирән,
Очрашырбыз әле яңадан [9, б. 338].

«Кама буе» исемле бу җыр Татарстанның Кайбыч районы Борындык авылында Сәрия Ногмановадан (1928 елда туган) 1955 елда язып алынган.

Яисә Татарстанның Ширәмәт районы Ширәмәт авылында Сания Гатауллинадан 1961 елда язып алынган «Сарман» җыры шулай ук язмышларны бутарга, авырлыклар китерергә сәләтле сугышның барлык ачысын тойган гади халыкка хас самими хисләрне чагылдыра:

Сарман буйларында салкын җилләр,
Туңам, иркәм, туңам, туның бир;
Аерылабыз, иркәм, аерылабыз,
Саубуллашыйк инде, кулың бир.
Сарман буйларын мин буйладым,
Буйлаганда сине дә уйладым.
Киткән чакларында кул бирмәдем,
Тагын кайтырсың дип уйладым [9, б. 341–342].

Җырның 1955 елда Татарстанның Кайбыч районы Борындык авылында Сәрия Әскәровадан, 1969 елда Омск өлкәсенең Большеречье районы Уба авылында Маһирә Хәлиловадан (1938 елда туган) язып алынган вариантлары да булу әсәрнең үз чорында шактый таралганлыгын күрсәтә.

Бу чорда фронттагы солдатлар тарафыннан иҗат ителгән җырларны да Бөек Ватан сугышы чорына караган лирик иҗатның аерым төркеме итеп билгеләү дөрес булыр. «Илне сагыну җыры», мәсәлән, 1958 елда Мордва Республикасының Беднодемьянский районы Таракан авылында Абдулла Үтәмешевтән (1899 елда туган) язып алынган:

Кырда карчыгалар кагынып йөри,
Коймаслармы кырлар тарысын?
Карчыга,
Күрешә алмыйча күңелем талчыга.
Илең сагынасыңмы дип сорыйсың,
Күрмисеңме йөземнең сарысын?
Карчыга,
Күрешә алмыйча күңелем талчыга.
Кычкырмачы, кәккүк, син кычкырма,
Эчкенәемне минем пошырма!
Кәккүгем,
Чит җирләрдә үтә яшьлегем!
Ил генәмә кайтып, сөйгән белән
Бер кавышыр көннәр булырмы?
Кәккүгем,
Чит җирләрдә үтә яшьлегем! [9, б. 127]

Бөек Ватан сугышына кадәр тарихта билгеле сугышлар вакытында чыгарылган җырлар да бу чорда сугышчылар арасында кабат популярлаша. Мәсәлән, «Окоп көе» дигән исем белән билгеле җыр 1941 елда А. Ключарёвның «Татар халык көйләре» җыентыгында басыла [11, б. 94]. Искәрмәсенә караганда, бу әсәр рус-япон сугышы чорында ук мәгълүм булган. А. Ключарёв җыентыгында нотасы белән бирелгән строфа түбәндәгедән гыйбарәт:

Солдатский ремень белән
Будылар билләремне шул.
Йөгереп китәрдәй булам ла,
Чит илләрдә үтә гомерем,
Сагындым илләремне шул [11, б. 94].

Бу җыр Ә. Абдуллинның «Көзге ачы җилләрдә» исеме белән 1960 елда Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсенә тапшырган җырлар дәфтәрендә дә урын алган, текст фольклор үзәгендә саклана [12].

«Солдат җыры» дип аталган түбәндәге җыр исә 1970 елда Төмән өлкәсе Түбән Тауда районы Байкал (Бохара) авылында Сабитова Сәрбидән (1895 елгы) магнитофон тасмасына язып алынган (язып алучы һәм нотага салучы – И. Кадыйров). XX йөзнең җитмешенче елларында да җырланганын исәпкә алганда, Бөек Ватан сугышыннан соң аның әле шактый популяр җырлар рәтендә булуы аңлашыла:

Чуен чүлмәк, аузы тар ла,
Пешәр солдат ашлары ла;
Кош-корт очып җитмәс җиргә,
Китә солдат башлары ла.
Таш казарма буйларына
Мылтыгымны сөядем;
Туган-үскән илләремә
Кайчан кайтыр сөягем? [13, б. 157–158].

Бу җыр – борынгы солдат җыры, аның элекке чорларда патша армиясендә татарлар язмышын тасвирлаган үрнәкләрдән булу ихтималы зур. Күрәсең, җырдагы актуаль вакыйгалар уңаеннан Бөек Ватан сугышы чорында ул кабат «яңарган».

Фронт җырлары дигәндә, татар лирик фольклорын тулыландыра торган тагын бер күренешкә тукталырга кирәк. Бу – Бөек Ватан сугышы елларында татар халык иҗатында эпистоляр жанрның үсеш кичерүе. Хат язышу – укымышлы татарлар тормышында гомер-гомергә зур урын алып торган традицияләрнең берсе. Сугыш чорында фронт белән тыл арасында хатлар йөргәнлеге мәгълүм. «Борынгыдан килгән гадәт буенча, кешеләр фронт белән тыл арасында йөрүче хатларын җырлар белән бизәделәр», – дип яза бу хакта И. Надиров [1, б. 93]. Чыннан да, сугышчыларның якыннарына язган хатларында җыр жанрының үтә популярлыгы күренә, фронттан килгән хатларда җыр текстларын еш очратырга мөмкин. Бу юлларда совет кешеләренең какшамас бердәмлегенә чын йөрәге белән ышанып, ватанын саклап сугышучы татар солдатының иленә мөнәсәбәте, якыннарына булган хисләре афористик дәрәҗәдә кыска, гади рәвештә, әмма шул ук вакытта югары сәнгать дәрәҗәсендә гәүдәләнеш тапкан. Ул елларда дөнья күргән газета битләрендә сакланган материаллар исә тылдагы хезмәт ияләренең дә фронттагы сугышчыларга язган хатларын җыр сүзләре белән бизәгәнлеге хакында хәбәр итә:

Безнең авыл уртасында
Җилферди кызыл әләм;
Илебез өчен көрәшүче
Каһарманнарга сәлам [10, б. 367].

1941–1945 еллардагы сугыш чоры җырлары дисәк тә, мондый иҗат шактый киң вакыт аралыгын алып тора. Аларга карата нәкъ менә сугыш вакыйгаларына гына бәйле барлыкка килгән һәм сугыш вакытында гына җырланган дигән катгый чикләрне куеп та булмый. Җырларның кайберләре – Бөек Ватан сугышына кадәр үк билгеле һәм хәтта әле бүген дә популярлыгын югалтмаган әсәрләр. Алар – тылда да, фронтта да халык белән бергә булган, кыенлыклар алдында югалып калмаска булышкан, сугыш елларында халыкка рухи көч өстәп торган җәүһәрләр.

Сугыш чоры җырлары – батырлыкка һәм матурлыкка мәдхия. Бөек Ватан сугышы чорында татар халкының поэтик иҗатына «Өй артымда шомыртым», «Таң атканда», «Озату», «Минем иркәм армиядә», «Зөмбел чәчәк», «Көтәм әле», «Бондюг», «Зөя» кебек озын көйле һәм бихисап кыска лирик җырлар өстәлде. Әлеге һ.б. җырлар, вакыт сынавын үтеп, бүгенге көнгә берничә вариантта килеп җиткәннәр. Аларның күбесе әле дә җырлана килә.

**Төп нәтиҗәләр**

Җыр поэзиясенең сугыш вакытында аеруча бай булуы, беренчедән, аның борынгы шигъри традицияләргә үк барып тоташкан булуыннан килә, икенчедән, шагыйрьләр һәм композиторлар иҗатының иң уңышлы үрнәкләренең халыклашып торуы, профессиональ җырчыларның халык әсәрләрен матбугат чаралары аша яңгыратулары да моңа йогынты ясый. Халык өчен авыр вакытта да җырлар онытылмаган, димәк, җырның поэтик бизәкләре дә яңа заманга күчкән. Элек-электән җырлана килгән әсәрләр яңа этапта әнә шулай киләчәккә хәрәкәт иткәннәр. Сугыш чорында җырланган җырларның һәрберсе мондый нәтиҗәгә лаек дип булмый, әлбәттә, әмма аларның күбесе, асылда, нәкъ менә вакыт сынавын үтеп, бүгенге көнгә килеп җитә алган. Жанрга хас булганча, төрле ситуациядә җырларның җиңел генә хәтергә килүе, кешеләрнең күңел халәтенә бәйле аларны еш башкарып торулары бу төр халык үрнәкләрен дәһшәтле чорның аерылмас юлдашы иткән. Эчтәлеге, темасы белән сугыш чорына караган җырлар дип бәяләнә торган иҗат татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә язып алынган яисә язма чыганакларда сакланып калган. Идел буеннан алып Себер киңлекләренәчә яңгыраган лирик фольклор

әсәрләре – ил өчен үтә катлаулы елларда татарларның чорына хас бердәмлегенә, ныклы рухына, сабырлыгына, хис-кичерешләренең байлыгына матди булмаган һәйкәл дип саналырга хаклы ядкарьләр.

**Әдәбият**


1. Надиров И. Бөек Ватан сугышы елларында татар халык җырлары. Казан утлары. 1957. № 3. Б. 93–98.
2. Надиров И. Н. Халык һәм җыр: Бөек Ватан сугышы чорында татар халык поэтик иҗаты. Казан: татар. кит. нәшр., 1961. 192 с.
3. Закирова И. Г. Народное творчество Булгарского периода: дис. ...к. фил. н. Казань, 2000. 24 с.
4. Мөхәммәтҗанова Л.Х. XVII-XVIII гасырларда халык иҗаты // Татар әдәбияты тарихы. 8 томда. 2 т. XV-XVIII гасырлар [төз. һәм фәнни мөх. Г.М. Дәүләтшин]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2022. Б. 227–243.
5. Урманчеев Ф. И. Татар халык иҗаты: югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2002. 335 б.
6. Сугыш уты белән өтелгән язмышлар. Фронтовик язучыларның хатлары һәм бүләкләү кәгазьләре җыентыгы. Төз., искәрмәләр авторы Ә. Шамова. Казан: Ихлас, 2014. 625 б.
7. Утлы еллар кайтавазы. Бөек Ватан сугышы чорында татар халык иҗаты. Кереш сүз авторы Ф.И.Урманчеев. Казан: Татар. кит. нәшр. , 2005. 199 б.
8. Мөхәммәтҗанова Л.Х. Дәһшәтле чор юлдашлары. Түгәрәк уен. 2025. № 2. Б. 26–32.
9. Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар. Томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче Надиров И. Н. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988, 488 б.
10. Татар халык иҗаты. Кыска җырлар (дүртьюллыклар). Томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче Надиров И. Н. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976, 488 б.2.
11. Ключарёв А. С. Татар халык көйләре. 1 нче китап / Төзүчесе һәм җыючысы А.С. Ключарёв. Казан: Татар. кит. нәшр., 1941. 248 б.
12. Көзге ачы җилләрдә // ТФА Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИнең Язма мирас үзәге, ФФ, 1960, колл. 1, п. 34а, сак. бер. 565а.
13. Кадыйров И.Ш. Татар халкының туй җырлары. Себер ареалы. Казан: ТӘһСИ, 2021. 188 б.


# ТАТАРСКИЕ НАРОДНЫЕ ЛИРИЧЕСКИЕ ПЕСНИ ВОЕННЫХ ЛЕТ


**Лилия Хатиповна Мухаметзянова**,
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ,
Россия, 420111, г. Казань, ул. Карла Маркса, д. 12,
lilmuhat@mail.ru.



В статье анализируется татарский песенный фольклор периода Великой Отечественной войны, созданный в тылу и на фронте. В качестве источников использовались тексты, введенные в научный оборот в академических изданиях «Татарское народное творчество», а также экспедиционные материалы разных лет, хранящиеся в Центре письменного наследия «Мирасханэ» АН РТ. В ходе исследования выявлены особенности лирических песен военных лет, распространенных на территории бывшего СССР среди татар. Доказано, что в текстах наблюдается обновление национальной эпической традиции.



**Ключевые слова**: татарский фольклор, период Великой Отечественной войны, лирическое творчество народа, жанр песни

**Для цитирования**: Мухаметзянова Л. Х. Татарские народные лирические песни военных лет // Tatarica. 2025. № 2 (25). С. 34–45. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-34-45